МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.09.2022 Казан ш № 860

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри

керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.09.2018 №904, 03.06.2019 №422, 14.11.2019 №1019, 25.06.2020 №460, 08.10.2020 №713, 17.12.2020 №861, 02.12.2021 №897 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне кертергә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының 2022
елның 12 сентябрендәге 860 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктта «(алга таба – ХМҮ)» сүзләрен «алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) мөрәҗәгать итүченең профилен яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.5 пунктны көчен югалткан дип таныргa;

1.7-1.9 пунктларны үз көчен югалткан дип таныргa;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә халыкның мәшгульлек үзәкләре тарафыннан күрсәтелә. Халыкның мәшгульлек үзәгенә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) һәм (яки) КФҮнең ерактагы эш урыны аша бирергә мөмкин.

КФҮ белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителми.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

билгеләнгән рәвештә эшсез дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган һәм һөнәри белем алган яки халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алынганда, булдырыла торган юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмәне (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә) мөрәҗәгать итүчегә җибәрү (бәяләмәнең киңәш ителә торган формасы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә, билгеләнгән рәвештә эшсез дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган һәм һөнәри белем алган яки халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алынганда, булдырыла торган юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеге стандартын раслау турында» 2022 елның 28 апрелендәге 275н номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә, билгеләнгән рәвештә эшсез дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган һәм һөнәри белем алган яки халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алынганда, булдырыла торган юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеге стандартына (алга таба – Стандарт) 5 нче кушымтада китерелгән);

Шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү (алга таба – бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

Халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә «Работа в России» бердәм цифрлы платформасын (https://www.trudvsem.ru/) (алга таба – Бердәм цифрлы платформа), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын (http://www.uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) кулланып, электрон документ формасында;

мөрәҗәгать итүчегә шәхсән кәгазь чыганакта.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән очракта, әлеге Регламентның 3.1 пунктында каралган административ процедуралар (гамәлләр), и-л пунктчаларыннан тыш, аның теләге буенча ул мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте дистанцион формада күрсәтелгән очракта, гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә Бердәм цифрлы платформадан, Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә бирелә.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан җибәрелгән көнне халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан кабул ителгән дип санала.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүче белән тестлар дистанцион формада Бердәм цифрлы платформадан тестлар узу кирәклеге турында хәбәр алынганнан соң өч календарь көн эчендә мөстәкыйль рәвештә уздырыла.

2.4.3. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчедән халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу зарурлыгы булуы турында мәгълүмат алынган көннән соң икенче эш көненнән соңга калмыйча, һөнәргә укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыра һәм җибәрә.

2.4.4. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчедән бизнес-план алынган көннән башлап ике эш көне эчендә аны бизнес-планның структурасына һәм эчтәлегенә белдерелә торган төп таләпләргә туры килү предметы буенча карап тикшерә.

2.4.5. Эшсез гражданнар тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә тәкъдим ителгән бизнес-планнар мәшгульлек үзәге каршында төзелгән, бизнес-планнарны бәяләү буенча Экспертлар советы (алга таба – Экспертлар советы) тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме бирү турындагы гаризаны теркәгән көннән башлап, календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көнлек чорда карап тикшерелә.

2.4.6. Экспертлар советы тарафыннан бизнес-планны эшләп бетерү зарурлыгы турында карар кабул ителгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәгеннән белдерү алган көннән башлап 10 календарь көн эчендә мөрәҗәгать итүчегә бизнес-планны эшләп бетерергә һәм яңадан карау өчен экспертлар советына юлларга кирәк.

2.4.7. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү турында гариза биргән көннән башлап биш эш көне узганчы, электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып, мөрәҗәгать итүченең шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алыну, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алу, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую турында белешмәләрен тикшерә.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче туры килә торган эш эзләү максатларында үзе исәптә тора торган халыкның мәшгульлек үзәгенә Стандартка карата 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча, Бердәм цифрлы платформаны, Татарстан Республикасы порталын кулланып, электрон документ рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) бирә.

2.6.2. Гариза мөрәҗәгать итүченең үз инициативасы буенча яисә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдиме белән риза булган очракта бирелә.

2.6.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану турында» 2013 елның 25 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану кагыйдәләре нигезендә алынган гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле булмаган, тикшерү сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган имза белән имзалана.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

Бердәм цифрлы платформадагы шәхси кабинет аша;

Татарстан Республикасы порталы аша;

КФҮ яки КФҮнең ерактагы эш урыны аша, халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгәндә, Бердәм цифрлы платформага керү мөмкинлеген тәэмин итеп.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә электрон формада гариза бирүдә ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә Бердәм цифрлы платформага, Бердәм порталга һәм Татарстан Республикасы порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм атутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуы булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге яки күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче зат риза булган очракта, әлеге системада мөрәҗәгать итүченең процедуралар узып бетерүен тәэмин итә.

2.6.5. Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән барган очракта, мөрәҗәгать итүче паспортын яисә аны алыштыра торган документны күрсәтә.

2.6.6. Вәкаләтле органнардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар һәм белешмәләр:

мөрәҗәгать итүче турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган яки халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан ведомствоара гариза нигезендә алынган, әлеге мөрәҗәгать итүчене туры килә торган эш эзләү максатларында дәүләт теркәвенә алганда, эшсез мөрәҗәгать итүчене теркәгәндә Бердәм цифрлы платформага кертелгән белешмәләр;

организмдагы бозылган функцияләрне һәм яшәештәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениеләре (алга таба – МСЭ учреждениесе) тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен кирәкле, инвалидлык турындагы белешмәләрне үз эченә алган индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә, ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек тәртибендә ФИР системасыннан;

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан соратыла торган, шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан соратыла торган, юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтында урнаштырылган «Һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусын тикшерү» гавами сервисында халыкның мәшгульлек үзәге

тарафыннан соратыла торган, һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусы турында белешмәләр.

2.6.7. Ведомствоара гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында җибәрелә.

2.6.8. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча һөнәри белем алганда яисә өстәмә һөнәри белем алган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатып торыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү мөрәҗәгать итүчедән, башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза алынган көннән башлап мөрәҗәгать итүче һөнәргә укып бетергәнчегә кадәр яисә әлеге дәүләт хезмәте күрсәтүне туктаткан көнгә кадәр туктатып торыла.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

шушы Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;

дөрес (төгәл) булмаган мәгълүматларны үз эченә алучы документлар тапшырылуы;

мөрәҗәгать итүчедә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме бирү турында шартнамәләр (алга таба – шартнамә) төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән бурычларның булуы;

халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру өчен каралган бюджет акчалары хисабыннан билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар тарафыннан финанс ярдәменең (субсидиянең, дәүләт ярдәменең, юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда бер тапкыр финанс ярдәменең) элегрәк алынуы.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатыла:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарны туры килә торган эш эзләү максатларында теркәү, эшсез гражданнарны теркәү, туры килә торган эшне сайлап алуга карата таләпләр, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 8 апрелендәге 460 номерлы карарына үзгәреш кертү турында, шулай ук Россия

Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында» 2021 елның 2 ноябрендәге 1909 номерлы карары белән расланган Эшсез гражданнарны теркәү кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданинны мөрәҗәгать итүче белән шартнамә төзелгән вакытка кадәр теркәү исәбеннән төшергән очракта;

гаризаны кире алган очракта;

мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә әңгәмә узу өчен әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан билгеләнгән датада килмәгән очракта;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 3.6.2 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән срокта тестларны узмаган очракта;

мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә тестлар узу өчен әлеге Регламентның 3.5.2 һәм 3.5.3 пунктларында каралган тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан билгеләнгән датада килмәгән очракта;

мөрәҗәгать итүчедән эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлы булмавы турында кабул ителгән карар турында мәгълүмат алынган очракта;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 3.9.4 пунктында күрсәтелгән срокта бизнес-план тапшырылмаган очракта;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан эшләп бетерелгән бизнес-планны әлеге Регламентның 3.10.2 пунктының «а» пунктчасында билгеләнгән срокта тапшырмаган очракта;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 3.10.6 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән срокта комиссия (эшче төркем) кисәтүләре буенча эшләп бетерелгән бизнес-планны тапшырмаган очракта;

мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан әлеге Регламентның 3.12.7 пунктында каралган тәртиптә билгеләнгән даталарда бер тапкыр финанс ярдәме бирү турында шартнамә төзү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәгән очракта;

мөрәҗәгать итүче бер тапкыр финанс ярдәме бирү турындагы шартнамәне имзалаудан баш тарткан очракта;

белдерүдә күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәге белән үзара хезмәттәшлек итә башларга тиешле, халыкның мәшгульлек үзәге белдерүендә күрсәтелгән датадан башлап 1 айдан артып киткән чорда мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белән хезмәттәшлек итмәве.

2.8.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар Бердәм цифрлы платформада, Татарстан Республикасы порталында теркәлә һәм халыкның мәшгульлек үзәге Бердәм цифрлы платформадан һәм Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерүне җибәрә.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән очракта чират көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләр белән халыкның мәшгульлек үзәгенә яисә КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итү көнен һәм вакытын килештерү телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.10.3. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.11.2. Гариза һәм документлар халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче тарафыннан ял көне яки эшләми торган бәйрәм көнендә җибәрелгән очракта, гариза җибәрү көне дип аның артыннан киләсе эш көне санала.

Гаризаны кабул итү турында белдерү гариза килгән көнне халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә җибәрелә.

## 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, халыкның мәшгульлек үзәкләре белгечләре тарафыннан түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

к) халыкның мәшгульлек үзәкләре хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

### 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре

түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

бүлмәләрнең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында Бердәм цифрлы платформада, мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында тулы мәгълүматлар булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срокларыныэ үтәлүе;

дәүләт хезмәте күрсәтү срокларының үтәлүе;

мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара хезмәттәшлек итү саны;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

халыкның мәшгульлек үзәге белгечләренең әлеге Регламентны бозуына прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара элемтәгә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.4. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

2.13.5. Күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.13.6. Мөрәҗәгать итүче КФҮ, КФҮ ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткән очракта, гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә теркәлгән көненнән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

2.13.7. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.13.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм цифрлы платформада, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

күрсәтү порталында, КФҮ аша алынырга мөмкин.

2.13.9. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексны мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән яки халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итә ала.

2.14.2. Халыкның мәшгульлек үзәкләрендә мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформага, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталына һәм Бердәм порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Бердәм цифрлы платформада, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында һәм Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибенә багышланган бүлекләрдә, Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге текст һәм график мәгълүмат рәвешендә урнаштырыла;

халыкның мәшгульлек үзәге бүлмәләрендә турыдан-туры стендларда, плакатларда һәм баннерларда текст һәм график рәвешендә урнаштырылган мәгълүмат, яисә халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәрләре белән консультация рәвешендә.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары

3.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

а) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

б) мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итү;

в) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыру һәм җибәрү;

г) бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү шартларын, аны бирү рәвешләрен һәм графигын кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүче белән әңгәмә уздыру;

д) эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашыруга сәләтлелекне һәм әзерлекне ачыклау, эшкуарлык эшчәнлеген башкарганда кирәкле белемнәр һәм күнекмәләргә ия булу максатында тестлар сайлау, билгеләү һәм үткәрү;

е) тест нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүче белән әңгәмә үткәрү;

ж) мөрәҗәгать итүчегә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы яки максатка ярашлы булмавы турында карар кабул итү максатында киңәшләр формалаштыру һәм җибәрү;

з) мөрәҗәгать итүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле бизнес-планны әзерләүне һәм кирәкле белемнәр һәм күнекмәләр алуны оештыру;

и) бизнес-планны карау;

к) мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча кирәкле белем һәм күнекмәләр, һөнәри белем яки өстәмә һөнәри белем алуда ярдәм күрсәтү;

л) дәүләт теркәвенә алынганда мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен күрсәтү;

м) техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, почта, электрон почта аша, техник мөмкинлек булганда, шул исәптән Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша һәм (яки) халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече шәхсән, телефон, почта, электрон почта һәм (яки) Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, консультацияләр бирә.

Процедураның максималь вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гариза кабул итү

Гариза һәм аңа беркетелгән документлар Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша халыкның мәшгульлек үзәгенә алына.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итү тиешле документлар килгән көнне Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша башкарыла.

Административ процедураның (гамәлнең) нәтиҗәсе булып гаризаны кабул итү тора.

Нәтиҗә Бердәм цифрлы платформада электрон формада теркәлә.

3.4. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче турында Бердәм цифрлы платформага кертелгән документлар һәм (яки) үзе тарафыннан тапшырылган яки халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан, шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып, ведомствоара гариза нигезендә алынган белешмәләрне анализлый.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүматларны анализлау.

3.4.2. Халыкның мәшгульлек дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим (алга таба – тәкъдим) формалаштыра һәм Бердәм цифрлы платформа аша аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә, тәкъдимдә түбәндәге мәгълүматлар була:

Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне карау нәтиҗәләрен җибәрү турында;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне карау нәтиҗәсен Бердәм цифрлы платформаны кулланып, халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрү срогы турында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим Бердәм цифрлы платформада автомат рәвештә формалаштырыла.

Үтәү вакыты: процедура тәкъдим формалаштырылган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим җибәрү.

3.5. Бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү шартларын, аны бирү рәвешләрен һәм графигын кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүче белән әңгәмә уздыру

3.5.1. Гариза алганнан соң халыкның мәшгульлек үзәге:

а) әңгәмәне дистанцион формада үткәрү өчен мөрәҗәгать итүче белән күрсәтелгән телефон номеры буенча элемтәгә керә;

б) мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү шартларын, аны бирү формалары һәм графигын кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында хәбәр итә;

в) мөрәҗәгать итүче тарафыннан гамәлгә ашыру өчен планлаштырылган эшкуарлык эшчәнлегенең формасы турындагы (шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алу, төзелә торган юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвенә алу, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу, һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында физик затны исәпкә кую), планлаштырылган икътисадый эшчәнлек төре турында белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка белешмәләрне мөрәҗәгать итүчедән аныклый һәм аларны Бердәм цифрлы платформага кертә;

г) әңгәмәнең формасын, аны уздыру көнен һәм нәтиҗәсен Бердәм цифрлы платформада терки.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: беренчел әңгәмә үткәрү.

3.5.2. Мөрәҗәгать итүче белән гаризада күрсәтелгән телефон номеры буенча дистанцион формада әңгәмә уздыру мөмкин булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге Бердәм цифрлы платформаны кулланып, әңгәмә уздыру өчен мөрәҗәгать итүче шәхсән килергә тиешле көнне һәм вакытны билгели һәм әлеге көндә һәм вакытта әңгәмә уздыру өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килү зарурлыгы турында белдерү җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән көндә һәм вакытта халыкның мәшгульлек үзәгенә әңгәмә узу өчен килмәгән очракта, Бердәм цифрлы платформаны кулланып,

мөрәҗәгать итүче өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат килү көнен һәм вакытын билгели, мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерүне җибәрә.

Үтәү вакыты: гариза кабул ителгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: әңгәмә үткәрү өчен гражданинның шәхсән килү көнен һәм вакытын билгеләү.

3.5.3. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә беренче тапкыр билгеләнгән датадан соң шәхси килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкның мәшгульлек үзәгенә иң күбе ике тапкыр кабат килү көнен билгели.

Халыкның мәшгульлек үзәге билгеләгән көннәрдә мөрәҗәгать итүче билгеләнгән беренче көнгә шәхсән килмәгән көннән башлап 15 календарь көн эчендә мөрәҗәгать итүче әңгәмә узу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәсә, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең әңгәмәгә килмәве турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформада терки, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатылган көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмаган срокта мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерү җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көндә һәм вакытта әңгәмә узу өчен килгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге әлеге Регламентның 3.6.1 пунктының «а»-«в» пунктчаларында күрсәтелгән гамәлләрне башкара.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: беренчел әңгәмә көнен һәм вакытын килештерү.

3.6. Эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашыруга сәләтлелекне һәм әзерлекне ачыклау, эшкуарлык эшчәнлеген башкарганда кирәкле белемнәр һәм күнекмәләргә ия булу максатында тестлар сайлау, билгеләү һәм үткәрү

3.6.1. Халыкның мәшгульлек үзәге:

а) мөрәҗәгать итүченең эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга сәләтлелеген һәм әзерлеген билгеләү, эшкуарлык эшчәнлеген башкарганда кирәкле белемнәр һәм күнекмәләргә ия булу максатында мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, тестларны сайлап ала һәм билгели (алга таба – тестлар);

б) Бердәм цифрлы платформаны кулланып, тестларны уздыру көнен билгели һәм мөрәҗәгать итүче белән килештерә, әгәр билгеләнгән тестлар Бердәм цифрлы платформада булмаса;

в) мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән тестлар, аларны узу тәртибе, формасы (төркемле яки индивидуаль) һәм сроклары турында мәгълүматны үз эченә алган хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: әңгәмә үткәрелгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: тест уздыру көнен мөрәҗәгать итүче белән килештерү һәм Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә хәбәр җибәрү.

3.6.2. Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан билгеләнгән тестлар Бердәм цифрлы платформада булган очракта, мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән тестларны Бердәм цифрлы платформасыннан файдаланып, хәбәрне алган көннән соң килгән җиде календарь көн эчендә үтәргә кирәклеге турында белдерүдә хәбәр ителә.

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан билгеләнгән тестлар Бердәм цифрлы платформада булмаган очракта, мөрәҗәгать итүчегә хәбәрдә күрсәтелгән датада һәм вакыт эчендә тестлар узу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килү кирәклеге турында белдерү белән хәбәр ителә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче белән әңгәмә уздырылган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тест үткәрү кирәклеге турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.6.3. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче өчен Бердәм цифрлы платформада булган тестларны узу һәм тестларның нәтиҗәләре белән онлайн режимда танышу өчен функциональ мөмкинлекләр тудыра.

Күрсәтелгән тест нәтиҗәләре тестлар үткән көнне Бердәм цифрлы платформада автоматик рәвештә формалаштырыла.

3.6.4. Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 3.6.2 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән срокта тестларны узмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә тиешле хәбәр җибәрелә.

Үтәү вакыты: дәүләт хезмәтен туктату турында карар кабул ителгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату.

3.6.5. Мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән тестлар Бердәм цифрлы платформада булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге (яисә килешү нигезендә җәлеп ителгән белгеч) мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхси килгән очракта аның белән тест уздыра.

Үтәү вакыты: гражданин тест узу өчен килгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан тест узу.

3.6.6. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә тест уздыру өчен шартнамә нигезендә белгечне җәлеп итү турындагы белешмәләрне, шул исәптән әлеге шартнамә реквизитлары турындагы белешмәләрне дә, Бердәм цифрлы платформага кертә.

Үтәү вакыты: процедура тестлар үткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан тестлар узу һәм Бердәм цифрлы платформада теркәү.

3.6.7. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче шәхсән килгән вакытта аның тарафыннан тестлар узу нәтиҗәләрен Бердәм цифрлы платформада терки, тест нәтиҗәләрен эшкәртә.

Үтәү вакыты: процедура тестлар үткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан тестлар узу һәм Бердәм цифрлы платформада теркәү.

3.6.8. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә тестларны узу өчен белдерүдә күрсәтелгән датада һәм вакытта килмәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүче өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат килү датасын һәм вакытын билгели, тиешле белдерүне мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Үтәү вакыты: тестлар узу өчен гражданин килмәгән көннән башлап бер эш көне дәвамында.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә кабат тест уздыру көнен һәм вакытын билгеләү.

3.6.9. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә беренче тапкыр билгеләнгән датадан соң шәхси килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкның мәшгульлек үзәгенә иң күбе ике тапкыр кабат килү көнен билгели.

Халыкның мәшгульлек үзәге тестларны узу өчен билгеләгән даталарда мөрәҗәгать итүче тестларны узу өчен билгеләнгән беренче датага шәхсән килмәгән көннән башлап 15 календарь көн эчендә мөрәҗәгать итүче тестларны узу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәсә, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең тестларны узуга килмәве турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформада терки, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерүне җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатылган көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату турында белдерү җибәрү.

3.7. Тест нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүче белән әңгәмә үткәрү

3.7.1. Халыкның мәшгульлек үзәге гаризада күрсәтелгән номер буенча, дистанцион формада тест уздыру нәтиҗәләре турында әңгәмә уздыру өчен, мөрәҗәгать итүче белән элемтәгә керә яисә, мөрәҗәгать итүче белән дистанцион формада әңгәмә уздыру мөмкин булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 3.5.2 пунктында билгеләнгән тәртиптә әңгәмә уздыру өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килүне билгели.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 3.6.3 һәм 3.6.7 пунктларында каралган тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан формалаштырылган тестларның нәтиҗәләрен эшкәртүне (анализлауны) тәмамлау көненнән соң киләсе эш көненнән соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тест нәтиҗәләрен аңлату.

3.8. Мөрәҗәгать итүчегә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы яки максатка ярашлы булмавы турында карар кабул итү максатында киңәшләр формалаштыру һәм җибәрү

3.8.1. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы яки максатка ярашлы булмавы турында киңәшләр (алга таба – киңәшләр) формалаштыра.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче белән тест нәтиҗәләре турында әңгәмә уздырган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: формалаштырылган киңәшләр.

3.8.2. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә белдерү җибәрә, анда түбәндәгеләр була:

а) мөрәҗәгать итүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы яки максатка ярашлы булмавы турында киңәшләр;

б) киңәшләр белән танышып чыкканнан соң, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы яки максатка ярашлы булмавы турында карар кабул итәргә һәм Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә кабул ителгән карар

турындагы мәгълүматны халыкның мәшгульлек үзәгенә белдерүне алган көннән соң өч календарь көн эчендә җибәрү тәкъдиме.

Үтәү вакыты: киңәшләр формалаштырылган көннән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә белдерү юллау.

3.8.3. Мөрәҗәгать итүчедән эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлы булмавы турында кабул ителгән карар турында мәгълүмат алынган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә тиешле хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчедән эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлы булмавы турында мәгълүмат алынганнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында хәбәр җибәрү.

3.9. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле бизнес-планны әзерләүне һәм кирәкле белемнәр һәм күнекмәләр алуны оештыру

3.9.1. Халыкның мәшгульлек үзәге, мөрәҗәгать итүчедән эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлы булуы турында кабул ителгән карар турында мәгълүмат алган очракта, гаризада күрсәтелгән мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресына түбәндәгеләрне җибәрә:

эшкуарлык эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча бизнес-план әзерләү өчен мәгълүмат һәм белешмә материаллар, шулай ук бизнес-планны әзерләү мәсьәләләре, бизнес-планны техник-икътисадый нигезләү мәсьәләләре һәм бизнес-планның структурасына һәм эчтәлегенә куела торган төп таләпләр турында мәгълүмат (алга таба – мәгълүмат һәм белешмә материаллар);

эшкуарлык эшчәнлеге нигезләре турында мәгълүмат (эшкуарлыкның икътисадый һәм хокукый аспектлары, эшкуарлыкка ярдәм итү формалары, икътисадый эшчәнлек төрләренең торышын һәм үсеш тенденцияләрен, товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең ихтыяҗын һәм тәкъдимнәрен, сайлап алынган эшчәнлек өлкәсендә конкуренция үсеше дәрәҗәсен маркетинг анализы юнәлешләре);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яки тиешле белгечләргә ярдәм структуралары эшчәнлеге юнәлешләре, белешмәләр өчен телефон номерлары, рәсми сайтларның адреслары турында мәгълүмат;

ярдәм алу өчен кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасына керүче оешмаларга һәм учреждениеләргә (финанс, мөлкәт, мәгълүмат һәм консультация) мөрәҗәгать итү мөмкинлеге, мондый оешмалар һәм учреждениеләр эшчәнлегенең юнәлешләре, аларның урнашкан урыннары, белешмәләр өчен телефон номерлары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларның адреслары турында мәгълүмат.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчедән эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы турында кабул ителгән карар турында мәгълүмат алынган көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат һәм белешмә материаллар җибәрү.

3.9.2. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән мәгълүмат һәм белешмә материалларның исемлеген, аларны җибәрү датасын Бердәм цифрлы платформада терки, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, әлеге Регламентның 3.8.6 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алган тиешле белдерү җибәрелә.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат һәм белешмә материалларны җибәрүнең икенче көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат һәм белешмә материаллар җибәрү турында белдерү юллау.

3.9.3. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә:

әзерләнгән бизнес-планны халыкның мәшгульлек үзәге билгеләгән срокта тапшыру зарурлыгы турында (ул мәгълүмат һәм белешмә материаллар алган көннән соң 45 календарь көннән артык була алмый), шулай ук эшләнгән бизнес-планны тапшыру ысулы турында;

әлеге Регламентның шушы пунктындагы икенче абзацта билгеләнгән срокта бизнес-планны тапшырмауның хокукый нәтиҗәләре турында.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчедән эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы турында кабул ителгән карар хакында мәгълүмат алганнан соң киләсе ике эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бизнес-планны вакытында тапшыру (тапшырмау) турында хәбәр итү.

3.9.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бизнес-планны мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат һәм белешмә материалларны җибәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокта тапшырмау халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан Бердәм цифрлы платформада теркәлә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә хәбәр итә.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче тарафыннан бизнес-план тапшырылмаган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында белдерү җибәрү.

3.10. Бизнес-планны карау

3.10.1. Халыкның мәшгульлек үзәге бизнес-планны структурасына һәм эчтәлегенә карата куела торган төп таләпләргә туры килү-килмәве буенча карый (кирәк булганда кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасына керүче оешмаларны һәм учреждениеләрне, яисә кирәкле белемгә һәм эш тәҗрибәсенә ия булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү өлкәсендәге белгечләрне җәлеп итеп) һәм бизнес-планны карау нәтиҗәләрен Бердәм цифрлы платформада терки.

Структурасына һәм эчтәлегенә карата куела торган төп таләпләргә туры килүе турында яисә, мөрәҗәгать итүчегә бетерергә кирәк булган искәрмәләр исемлеген күрсәтеп, аны эшләп бетерү кирәклеге турында карар кабул итү халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан бизнес-планны карау нәтиҗәсе булып тора.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчедән бизнес-план алынганнан соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: бизнес-планның төп таләпләргә туры килүе яки аны эшләп бетерү кирәклеге турында карар кабул итү.

3.10.2. Халыкның мәшгульлек үзәге, бизнес-планны эшләп бетерү кирәклеге турында карар кабул ителгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша белдерү җибәрә, анда түбәндәгеләр була:

а) бизнес-планны эшләп бетерергә һәм эшләп бетерелгән бизнес-планны халыкның мәшгульлек үзәгенә белдерү алган көннән соң килә торган сигез календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрергә кирәклеге турында мәгълүмат;

б) бизнес-планны эшләп бетергәндә төзәтергә кирәк булган искәрмәләр исемлеге.

Үтәү вакыты: бизнес-планны эшләп бетерергә кирәк дигән карар кабул ителгән көнне.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бизнес-планны эшләп бетерергә кирәклеге турында хәбәр җибәрү.

3.10.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан эшләнгән бизнес-планны әлеге Регламентның 3.10.2 пунктындагы «а» пунктчасында билгеләнгән срокта тапшырмау халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан Бердәм цифрлы платформада теркәлә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктаткан көннән соң киләсе эш көненнән соңга калмаган срокта халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә тиешле белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче тарафыннан эшләп бетерелгән бизнес-план тапшырылмаган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында белдерү җибәрү.

3.10.4. Бизнес-план структурасына һәм эчтәлегенә куела торган төп таләпләргә туры килгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге бизнес-планны карау өчен экспертлар советына җибәрә, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерү җибәрә, анда экспертлар советы тарафыннан мөрәҗәгать итүченең бизнес-планын карау чоры күрсәтелгән була.

Үтәү вакыты: халыкның мәшгульлек үзәге бизнес-планның төп таләпләргә туры килүе турында карар кабул иткән көннән соң киләсе эш көне узганчы.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең бизнес-планын карау өчен эксперт советына җибәрү.

3.10.5. Экспертлар советы халыкның мәшгульлек үзәгеннән алынган бизнес-планны карый.

Үтәү вакыты: халыкның мәшгульлек үзәгеннән мөрәҗәгать итүченең бизнес-планын алганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча.

3.10.6. Экспертлар советы тарафыннан бизнес-планны эшләп бетерү кирәклеге турында карар кабул ителгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге

мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә белдерү җибәрә, анда түбәндәгеләр була:

а) экспертлар советы искәрмәләре буенча бизнес-планны эшләп бетерергә һәм эшләп бетерелгән бизнес-планны халыкның мәшгульлек үзәгенә белдерү алган көннән соң килә торган 10 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрергә кирәклеге турында мәгълүмат;

б) экспертлар советы искәрмәләре буенча бизнес-планны эшләп бетергәндә төзәтергә кирәк булган искәрмәләр исемлеге.

Үтәү вакыты: бизнес-планны эшләп бетерергә кирәк дигән карар кабул ителгән көнне.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бизнес-планны эшләп бетерергә кирәклеге турында хәбәр җибәрү.

3.10.7. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан эшләнгән бизнес-планны әлеге Регламентның 3.10.6 пунктындагы «а» пунктчасында билгеләнгән срокта тапшырмау халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан Бердәм цифрлы платформада теркәлә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә тиешле хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында карар кабул ителгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында белдерү җибәрү.

3.10.8. Экспертлар советы тарафыннан бизнес-планны килештерү турында карар кабул ителгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге:

а) бизнес-планның экспертлар советы тарафыннан килештерелүе турында Бердәм цифрлы платформага мәгълүматлар кертә;

б) мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа аша түбәндәгеләрне җибәрә:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә;

белдерү, анда түбәндәгеләр була:

белдерү алынган көннән соң килә торган өч календарь көннән соңга калмыйча, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, эшкуарлык эшчәнлеген башкару өчен кирәкле булган белемнәрне һәм күнекмәләрне алу ихтыяҗы булуы турында яисә халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте юлламасы буенча, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен, һөнәри белем алу яисә өстәмә һөнәри белем алу зарурлыгы турында мәгълүматны җибәрү кирәклеге турында;

экспертлар советы тарафыннан бизнес-планны килештерү турында карар кабул ителгән көннән соң 30 календарь көн узганчы яисә һөнәри белем алу яисә өстәмә һөнәри белем алу тәгәлләнгән көннән соң 30 календарь көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә шәхси эшкуар, төзелә торган юридик зат, крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алыну яисә физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым түләүчене исәпкә куюны (алга таба – дәүләт теркәве) гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, булдырыла торган юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда,

физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме бирү тәртибен раслау турында» 2012 елның 29 маендагы 431 номерлы карарында (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 2012 елның 29 маендагы 431 номерлы карары) каралган тәртиптә мөрәҗәгать итүченең, халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килү юлы белән, бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү турында гариза бирә алуга хокуклы булуы турында мәгълүмат.

Үтәү вакыты: экспертлар советы бизнес-планны килештерү турында карар кабул иткән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә, белдерү җибәрү.

3.11. Мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча кирәкле белем һәм күнекмәләр, һөнәри белем яки өстәмә һөнәри белем алуда ярдәм күрсәтү

3.11.1. Халыкның мәшгульлек үзәге, мөрәҗәгать итүчедән эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле белемнәрне һәм күнекмәләрне алу ихтыяҗы булуы турында мәгълүмат алган очракта:

а) Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә мөрәҗәгать итүче сайлаган икътисадый эшчәнлек төре буенча (булмаса – охшаш вариант буенча) эшчәнлек башкара торган, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруда уңай тәҗрибәсе булган юридик затларның, шәхси эшкуарларның, фермерларның беренчел исемлеген (алга таба – исемлек) төзи;

б) беренчел исемлеккә кертелгән юридик затларның вәкилләре, шәхси эшкуарлар, фермерлар белән өстәмә күнекмәләр алырга теләгән мөрәҗәгать итүченең аларга мөрәҗәгать итү мөмкинлеген һәм вакытын килештерә;

в) Бердәм цифрлы платформа аша мөрәҗәгать итүченең өстәмә күнекмәләр алу өчен мөрәҗәгать итү мөмкинлеге һәм вакыты килештерелгән юридик затлар, шәхси эшкуарлар, фермерлар исемлеген төзи (алга таба – актыккы исемлек).

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчедән эшкуарлык эшчәнлеген башкару өчен кирәкле белем һәм күнекмәләр алуга ихтыяҗ турында мәгълүмат алынган көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: актыккы исемлекне төзү.

3.11.2. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа аша түбәндәгеләрне җибәрә:

а) эшкуарлык эшчәнлеген башкаруның уңай тәҗрибәсе булган мисаллар, мөрәҗәгать итү сроклары, мөрәҗәгать итү урыннары, юридик затларның, шәхси эшкуарларның, фермерларның элемтә белешмәләре турында мәгълүмат булган актыккы исемлек;

б) белдерү, анда түбәндәге мәгълүмат була:

актыккы исемлектәге мәгълүматлар нигезендә, эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен кирәкле күнекмәләрне алу өчен, юридик затларга, шәхси эшкуарларга, фермерларга мөрәҗәгать итү зарурилыгы турында;

исемлек белән танышып чыгу турындагы белешмәләрне исемлек алынган көннән соң киләсе өч календарь көн узмаган срокта халыкның мәшгульлек үзәгенә Бердәм цифрлы платформа аша җибәрү кирәклеге турында.

Үтәү вакыты: актыккы исемлек төзелгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә актыккы исемлекне җибәрү.

3.11.3. Халыкның мәшгульлек үзәге, башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укытуны, аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыра һәм аны Бердәм цифрлы платформа аша аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән риза булган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү мөрәҗәгать итүчедән, башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза алынган вакыттан башлап мөрәҗәгать итүче һөнәргә укып бетергәнчегә кадәр яисә әлеге дәүләт хезмәте күрсәтүне туктаткан көнгә кадәр туктатып торыла.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчедән эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу яисә өстәмә һөнәри белем алу зарурлыгы турында мәгълүмат алынган көннән соң икенче эш көненнән соңга калмаган чорда.

Процедураның нәтиҗәсе: һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алуны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәкъдимен формалаштыру һәм җибәрү.

3.12. Дәүләт теркәвенә алынганда мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен күрсәтү

3.12.1. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче тарафыннан бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү турында гариза бирелүе турындагы мәгълүматны Бердәм цифрлы платформага кертә һәм гражданинга тиешле белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче тарафыннан бер тапкыр ярдәм күрсәтү турында гариза бирелгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү турында гариза бирелүе турындагы мәгълүматны кертү.

3.12.2. Халыкның мәшгульлек үзәге электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып, мөрәҗәгать итүченең шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алыну, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алу, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую турында белешмәләрен тикшерә.

Үтәү вакыты: бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү турында гариза бирелгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт теркәве турындагы мәгълүматларны тикшерү.

3.12.3. Бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү турында гариза биргән мөрәҗәгать итүчегә карата халыкның мәшгульлек үзәге, ТР Министрлар Кабинетының 2012 елның 29 маендагы 431 номерлы карарында күрсәтелгән тәртиптә мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү яисә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәменең күләме, аны бирү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 29 маендагы 431 номерлы карары нигезендә билгеләнә.

3.12.4. Халыкның мәшгульлек үзәгенең әлеге Регламентның 3.12.3 пунктында күрсәтелгән карарлары шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алу, булдырыла торган юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвенә алу, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу, һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында физик

затны исәпкә кую вакытында бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү турындагы боерык рәвешендә (киңәш ителә торган формасы Стандартка 2 нче кушымтада китерелгән) яисә шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алу, булдырыла торган юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвенә алу, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу, һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында физик затны исәпкә кую вакытында бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында карар рәвешендә (киңәш ителә торган формасы Стандартка 3 нче кушымтада китерелгән), тиешенчә рәсмиләштерелә.

3.12.5. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: боерык чыгарылган көннән башлап бер эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән карар турында хәбәр җибәрү.

3.12.6. Халыкның мәшгульлек үзәге:

а) бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү турында шартнамә проектын (алга таба – шартнамә) төзи (шартнамәдә чагылдырырга киңәш ителә торган белешмәләрнең составы, киңәш ителә торган формасы Стандартка 4 нче кушымтада китерелгән);

б) мөрәҗәгать итүче белән шартнамә төзү өчен, халыкның мәшгульлек үзәгенә килү датасын һәм вакытын килештерә, Бердәм цифрлы платформага тиешле мәгълүматларны кертә;

в) мөрәҗәгать итүчегә, шартнамә төзү өчен, Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә халыкның мәшгульлек үзәгенә килү көне турында мәгълүматны үз эченә алган белдерүне җибәрә.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү турында боерык чыккан көннән соң бер эш көненнән соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: белдерүне җибәрү.

3.12.7. Мөрәҗәгать итүче шартнамәне төзү өчен күрсәтелгән көндә һәм вакытта халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат килү көнен һәм вакытын билгели, Бердәм цифрлы платформа аша мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче шартнамә төзү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәгән көннән соң бер эш көне дәвамында.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә шартнамә төзү өчен кабат килү көнен билгеләү.

3.12.8. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә беренче тапкыр билгеләнгән датадан соң шәхси килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкның мәшгульлек үзәгенә иң күбе ике тапкыр кабат килү көнен билгели.

3.12.9. Халыкның мәшгульлек үзәге шартнамә төзү өчен билгеләгән даталарда мөрәҗәгать итүче тестларны узу өчен билгеләнгән беренче датага шәхсән килмәгән көннән башлап 15 календарь көн эчендә мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәсә, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең тестларны узуга килмәве турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформада

терки, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерүне җибәрә.

Үтәү вакыты: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында карар кабул ителгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында белдерү җибәрү.

3.12.10. Мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне һәм вакытта килгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче белән шартнамә төзи.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче шартнамә төзү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: шартнамә төзү.

3.12.11. Мөрәҗәгать итүче шартнамә төзүдән шәхсән килгән вакытта баш тарткан очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: дәүләт хезмәтен туктату турында карар кабул ителгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында белдерү җибәрү.

3.12.13. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче белән төзелгән шартнамә турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформага кертә.

Үтәү вакыты: шартнамә төзелгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: төзелгән шартнамә турында мәгълүмат урнаштыру.

3.12.14. Бердәм цифрлы платформада төзелгән шартнамәләрнең реестры формалаштырыла һәм алып барыла.

3.12.15. Халыкның мәшгульлек үзәге шартнамә шартлары нигезендә мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен күчерә.

3.12.16. Халыкның мәшгульлек үзәге аңа бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен күчерү турында белдерү җибәрә, анда, шул исәптән, алга таба мөрәҗәгать итүченең әлеге шартнамә шартлары нигезендә алга таба халыкның мәшгульлек үзәге белән хезмәттәшлек итү тәртибе турында мәгълүмат була, шулай ук Бердәм цифрлы платформаны кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү көнендә.

Процедураның нәтиҗәсе: белдерүне җибәрү.

3.12.17. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә бер тапкыр түләнгән финанс ярдәмнең максатчан тотылуын раслаучы документларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 29 маендагы 431 номерлы карарында билгеләнгән срокта тапшыра.

3.12.18. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчедән әлеге пунктта күрсәтелгән документларның алынуы турында раслап, мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчедән документлар алынган көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: документларны алу турында белдерү җибәрү.

3.12.19. Халыкның мәшгульлек үзәге:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 29 маендагы 431 номерлы карары, шулай ук шартнамә нигезендә тапшырылган документларның тулылыгын тикшерүне гамәлгә ашыра;

тапшырылган документларны тикшерә;

тапшырылган документлар нигезендә Бердәм цифрлы платформага мәгълүматлар кертә;

Бердәм цифрлы платформада расланган чыгымнар исемлеген терки.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче тарафыннан бер тапкыр түләнгән финанс ярдәмен максатчан тотуны раслаучы документлар тапшырылган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган чыгымнар исемлеген теркәү.

3.13. Техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү

Техник хатаны төзәтү мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.13.1. Мөрәҗәгать итүче, техник хата ачыкланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенә түбәндәгеләрне тапшыра:

- техник хатаны төзәтү турында гариза (тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән);

- техник хатаны төзәтү кирәкле булган, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документ (документлар).

3.13.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

- техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм терки;

- техник хата булган документларны яңадан рәсмиләштерә;

- нигезләр булган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына үзгәрешләр кертә;

- мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән техник хатаны бетерү (бетерүдән баш тарту) турында хәбәр итә.

3.13.3. Хатаны төзәтү «төзәтелгән» дип язылган булырга, документка кул куйган затларның имзасы белән расланган, шулай ук төзәтү датасы куелган булырга тиеш.

Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документлар мөрәҗәгать итүченең шәхси эшенә куела.

Процедураны үтәү вакыты: гариза теркәлгән көннән соң бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза, техник хатаны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә техник хатаны бетерү (бетерүдән баш тарту) турында хәбәр итү.»;

4 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольне халыкның мәшгульлек үзәге директоры яки аның вәкаләтле хезмәткәре башкара.»;

4.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне агымдагы тикшерүдә тоту әлеге Регламентны, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш

белән тәэмин итү өлкәсендә, аларга белешмәләр кертү тәртибен, срокларын һәм формаларын, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрларында булган мәгълүматларның төрләре исемлеген дә кертеп, дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның регистрларын алып бару тәртибе турында» 2021 елның 6 декабрендәге 871н номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә, аларга белешмәләр кертү тәртибен, срокларын һәм формаларын, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрларында булган мәгълүматларның төрләре исемлеген дә кертеп, дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның регистрларын алып бару тәртибен үтәү һәм башкаруга карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

икенче абзацта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламент (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.»;

4.4 пунктта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе;

5.1 пунктта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктта:

икенче абзацында «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $15^1$ статьясында күрсәтелгән» сүзләрен өстәргә»;

сигезенче абзацта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

5.9 пунктта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип
танылган гражданнарга һәм һөнәри
белем бирүне үткән яисә мәшгульлек
хезмәте органнары юлламасы буенча
өстәмә һөнәри белем алган
гражданнарга шәхси эшкуар

сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«__________________ халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе

__________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
түбәндәге адрес буенча яши __________________________________________________

_____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

_____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ исеме, аның сериясе,

_____________________________________________________________________
номеры, бирелгән датасы, документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ____________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________,
халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан 20___ елның ____________ бирелгән №______________ җибәрелгән.
Үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны алуга риза

_____________________________________________________________________
(халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә

_____________________________________________________________________
яисә почта аша язмача, электрон почта, мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша)

_______________________________________________________________________________

«__» __________ 20__ ел. ____________________ ________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)

2-4 нче кушымталарны үз көчен югалткан дип танырга.